КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 май г.Казань № 624

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урынынннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территория-сенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими яшәү урынынннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

исемендә «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Даими яшәү урынынннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибендә:

исемендә «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

1.1 пунктта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

1.2 пунктның икенче абзацында «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

1.3 пунктта:

«билгеләнә торган» сүзләрен «расланган» сүзенә алмаштырырга

«Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы» сүзләреннән соң «2023 елның беренче яртыеллыгына» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктның икенче абзацында «документлар» сүзләреннән соң «(шул исәптән аларның гамәлдә булу срогы тәмамланган)» сүзләрен өстәргә, «Россия Федерациясе» сүзләреннән соң «, 1974 елгы СССР гражданы паспорты (шәхесне таныклый торган башка документлары булмаган затлар өчен), Украинада гражданлыгы булмаган затның яшәүгә рөхсәте, Россия Федерациясендә гражданлыгы булмаган затның вакытлыча шәхес таныклыгы, Украина гражданлыгын һәм шәхесен таныклый торган башка документлары булмаган затка бирелгән Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында таныклык,» сүзләрен өстәргә.

2.2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының 2022 елның 13 октябренә кадәр теләсә кайсы чорда Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү буенча теркәлү фактын раслый торган, шул исәптән Украинаның компетентлы органы тарафыннан бирелгән документ, ягъни: әлеге пунктның өченче абзацында каралган, яшәү урыны буенча теркәлү турында билгесе булган документ, йорт кенәгәсеннән өземтә, прописка карточкасы, адрес турында белешмә кәгазе, ID-картга бирелгән яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмә кәгазе, бердәм дәүләт демографик реестрыннан яшәү урыны теркәлү турында өземтә, әлеге реестрга мәгълүматларны кертү турында белешмә кәгазе, ятим баланың, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланың яисә эшкә сәләтсез затның Херсон шәһәрендәге яки Херсон өлкәсенең бер өлешендәге мәгариф оешмасында, медицина оешмасында, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмада, яисә башка оешмада (шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен) булу фактын раслый торган яисә 18 яше тулмаган затның, Херсон шәһәрендәге яки Херсон өлкәсенең бер өлешендәге ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесенә урнашу фактын раслый торган документ, яисә әлеге мәгълүматлар бирелгән башка документ, яисә Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә күчемсез мөлкәткә милек хокукын раслый торган документ, гражданның Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган аңлатмасын теркәп, әгәр мондый гражданның әлеге территорияләрдә аның даими яшәүфактын раслый торган документ булмаган булса. Шул ук вакытта Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган документлары булмаган балигъ булмаган балаларның яшәү урыны итеп аларның ата-аналары, уллыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) һәм башка законлы вәкилләренең яшәү урыны танылa, ә ата-аналары аерым яшәгән очракта, балаларның яшәү урыны ата-аналарның килешүе буенча билгеләнә.»;

2.3 пунктта:

«гражданнар» сүзеннән соң «Украинаның, йә Херсон өлкәсенең, йә Россия Федерациясенең компетентлы органы тарафыннан 2022 елның 13 октябренә кадәр бирелгән» сүзләрен өстәргә;

«аларның яшәвен раслый торган» сүзләрен «аларның яшәве турында белешмәләр булган» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

Сертификат аның гаилә әгъзаларына элек бирелгән сертификат алу гаризасында күрсәтелмәгән гаилә әгъзасына сертификат биргәндә бер гаиләгә социаль түләү күләме (социаль түләүләрнең гомуми күләме) яисә мондый гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган социаль түләүләрнең гомуми күләме, сертификат (сертификатлар) бирү срогына һәм социаль түләүдән (түләүләрдән) файдалану срогына бәйсез рәвештә, Фонд акчалары исәбеннән һәм әлеге Тәртипнең 1.3 пункты нигезендә гаиләнең барлык әгъзаларына билгеләнә торган, беренче сертификатны бирү датасына торышы буенча социаль түләүнең (түләүләрнең) түләү күләменнән артмаска тиеш.»;

3.2 пунктта «Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләрен «Россия Федерациясе территориясендә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.9 пункт өстәргә:

«3.9. Министрлык гражданга социаль түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта, граждан кире кагу өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң, социаль түләү бирү турында гаризаны кабат бирергә хокуклы.»;

3.9 пунктны 3.10 пункт дип санарга;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Яңа сертификат биргәндә социаль түләү күләмен исәпләү юкка чыгарылган сертификатны бирү датасына карап башкарыла.»;

4.1 пунктның өченче абзацын дүртенче абзац дип санарга;

4.4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаилә әгъзаларын яңа сертификатка керткән очракта яисә аларга карата гариза элегрәк бирелмәгән гаилә әгъзалары, сертификат хуҗасы, элек бирелгән сертификатны юкка чыгару турында гариза белән, әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында каралган документларны, гариза бирелмәгән гаилә әгъзаларына язып, яңа сертификат бирү турында гариза белән Министрлыкка мөрәҗәгать итә. Шул ук вакытта яңа сертификат бирү әлеге Тәртипнең 2.3 - 2.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла, ә яңа сертификат буенча социаль түләү күләмен исәпләү, юкка чыгарылган сертификатны бирү датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрының һәм яңа сертификатны бирү датасына яңа сертификат бирелгән датага гаиләнең фактик составының бәясеннән чыгып башкарыла.»;

дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин